КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1463

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 70 нче; 2022 ел, 11 февраль, 118 нче; 2022 ел, 8 апрель, 329 нчы, 2022 ел, 13 май, 440 нчы, 2022 ел, 23 июнь, 599 нчы, 2022 ел, 15 август, 821 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.1. | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | китапханә фондларын булдыру, исәпкә алу, өйрәнү, физик сакланышын һәм иминлеген (фондларны цифрлаштыруны кертеп) тәэмин итү | 8 215 940,0 |
| | | китапханә фондын (истәлекле китапларны кертеп) тотрыклыландыруны, реставрацияләүне һәм консервацияләүне гамәлгә ашыру | 6 161 955,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | документларны библиографик эшкәртү һәм каталоглар төзү | 5 477 293,33 |
| | | китапханә эше өлкәсендә методик яктан тәэмин итү | 4 792 631,67 |
| | | массакүләм мәдәни чаралар үткәрүне оештыру | 4 107 970,0»; |

2.18 пунктның 4 графасында «305 427 212,16» саннарын «315 518 488,74» саннарына алмаштырырга;

2.21 пунктның 4 графасында «8 358 541,9» саннарын «8 426 541,9» саннарына алмаштырырга;

2.22 пунктның 4 графасында «5 896 400,0» саннарын «5 928 800,0» саннарына алмаштырырга;

3.1 пунктның 4 графасында «704 325 100,0» саннарын «863 725 100,0» саннарына алмаштырырга;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.3. | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару | 38 357 026,59 |
| | | табиблар рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү | 3 517 273,41 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (проектлар белән идарә итү) | 22 104 030,0 |
| | | оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (сатып алуларны оештыру) | 195 048 600,0»; |

3.4 пунктның 4 графасында «412 392 500,0» саннарын «662 727 480,0» саннарына алмаштырырга;

4.1 пунктның 4 графасында «17 007 200,0» саннарын «10 516 200,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни өлкәсенең аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнар һәм аларның күләмнәрендә 2.1 пунктның 4 графасында «64,3» саннарын «67,61» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин